ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПИЖМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЫЖМАРА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» апреля 2023ел. № 17

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пижмар авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалтуын тану турында**

Гамәлдәге законнар үзгәрү белән бәйле рәвештә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Пижмар авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пижмар авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРА:

1.1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пижмар авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 14 мартындагы 4 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

1.2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Пыжмара авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контроль үткәргәндә тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 15 мартындагы 15 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) «Җирлекләр» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге башлыгына калдырырга.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Заляев Р.Х.